КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 15 апрель г.Казань № 250

Татарстан Республикасы төзелеш тармагында мәшгуль булган беренче разрядлы эшче хезмәте өчен түләүнең уртача айлык күләме турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының $8^3$ статьясындагы 7 өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Төзелеш ресурслары бәяләрен мониторинглау турында» 2016 елның 23 декабрендәге 1452 номерлы карары белән расланган Төзелеш ресурслары бәяләрен мониторинглау кагыйдәләренең $22^1$ нче пункты нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Төзелешнең смета кыйммәтен билгеләү максатлары өчен Татарстан Республикасының төзелеш тармагында эшләүче беренче разрядтагы эшче хезмәте өчен түләүнең уртача айлык күләмен 2020 елга 23 959,92 сумга тигез итеп билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының төзелеш тармагында эшләүче беренче разрядтагы эшче хезмәте өчен түләүнең уртача айлык күләме турында» 2020 ел, 17 ноябрь, 1030 нчы карары үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин